ТЕРРИТОРИАЛЬНАЯ ИЗБИРАТЕЛЬНАЯ КОМИССИЯ
САБИНСКОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район, п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТЕРРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА РАЙОНЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел./ факс (84362) 2-40-66

# РЕШЕНИЕ

**19 ноября 2018 г.** **№ 76/5**

## Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Югары Симет авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2018 нче елның 18 ноябрендә кабул ителгән Җирле референдум нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 56 статьясы нигезендә, участок комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре турында участок комиссиясенең 2018 елның 19 ноябрендәге беркетмәсенең беренче нөсхәсе күрсәткечләре нигезендә,2018 елның 18 ноябрендә узган җирле референдум нәтиҗәләре турында беркетмә төзелде, аның нигезендә:

Референдумда катнашучылар исемлегенә тавыш бирү тәмамлануга 425 катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә ,референдумда катнашучылар саны - 386, бу муниципаль берәмлек территориясендә референдумда катнашучылар исемлегенә кертелүчеләрнең 90.82% ын тәшкил итә. Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

референдумда катнашучыларның 380(98.45%) «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде, Бу тавыш бирүдә катнашкан референдумда катнашучыларның 50 процентан артыгын тәшкил итә;

«Юк» позициясе өчен референдумда катнашучыларның 6сы тавыш бирде, бу 1.55% тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Саба районы территориаль сайлау комиссиясе карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны 2018 нче елның 18 ноябрендә узган дип танырга, референдум нәтиҗәләре - гамәлдә дип танырга.

2. "2019 елда Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә ризамы ьыелган акчалар җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен тотылачак.

- Югары Симет авылында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау;
-Түбән Симет авылында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау.

3.Җирле референдум нәтиҗәләрен «Саба таннары» газетасында бастырып чыгарырга яки Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Саба районы Югары Симет авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы Саба районы
территориаль сайлау комиссиясе рәисе М.В.Галиуллин

Татарстан Республикасы Саба районы
территориаль сайлау комиссиясе
сәркәтибе К.Ф.Хисамиев